РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Асеевского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района
ул. Центральная, д.38Б, с. Асеево,
Азнакаевский район, 423310

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әсәй авыл җирлеге
Башлыгы
Үзәк ур., 38Б нче йорт, Әсәй авылы, Азнакай
районы, 423310

Тел./факс(885592)43-2-37, 43-3-27; E-mail: Asv.Azn@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» ноябрь 2019 ел. № 21

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 30 ноябрендә сәгать 14.00да үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Яшьлек урам, 1нче йорттан 56нчы йортка кадәр.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Митрәй авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 30 ноябрендә сәгать 16.00да үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Тукай урамы, 1нче йорттан 53нче йортка кадәр, Тау Асты урамы, 1нче йорттан 23нче йортка кадәр, Мәктәп урамы, 1нче йорттан 18нче йортка кадәр.
3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Әсәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты – 30 ноябрь 2019 ел 14.00 сәг.тән 15.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты – 30 ноябрь 2019 ел 16.00 сәг.тән 17.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын үткәрү урыны –Митрәй авылы, Тукай ур., 15Г йорты, Митрәй авыл мәдәният йорты залы ;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 24 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Әсәй авылы, Үзәк урамы, 38Б йорты;
- сайлау хокукына ия булган Митрәй торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Әсәй торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Әсәй авыл җирлеге Митрәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Митрәй авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Митрәй авылы Тау асты, Тукай урамнары буенча вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Митрәй авылында юлларны кардан чистарту;
- Митрәй авылында җәйге чорда территорияне чабу;
- Митрәй авылында (зиарат, мәчет, мәдәният йорты территорияләрендә) коры агач, куаклар кисү, чабу;
- Митрәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Митрәй авылында бәйрәм чараларын («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») оештыру һәм үткәрү;
- Митрәй авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәле территориясенең чикләрен алмаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Митрәй авылы, Тукай ур., 15Г йорты адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әсәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: З.Ә. Идрисов.